КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь г.Казань № 1206

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү чараларын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын алга таба тормышка ашыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10ысына кадәр, Татарстан Республикасының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе секретариатына бу карар белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру турында хисап кертүне;

юл хәрәкәтендә катнашучыларга һәркем өчен мөмкин булган мәгълүмати ресурслар ярдәмендә, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларда Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы сәхифәсенә сылтама урнаштырып, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны автоматик фото- һәм видеофиксацияләү системалары эше нәтиҗәләре буенча чыгарылган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча карарларның күчермәләрен Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге турында хәбәр итүне тәэмин итәргә;

балалар төркеменәрен йөртүне оештырган вакытта «ГЛОНАСС+112" бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган спутник навигациясе системасы белән җиһазландырылган автобусларны кулланырга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2021 елның 1 мартына кадәр, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, автомобиль юлларының куркыныч авария участокларын, юл-транспорт һәлакәтләренең еш була торган потенциаль урыннарын һәм һәлак булучылар белән берәр юл-транспорт һәлакәтләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләүне һәм 2021 елның 1 июленә кадәр аларны бетерү буенча планлаштырылган чараларны төгәлләүне;

2021 елның 1 июленә кадәр федераль әһәмияттәге һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларындагы юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен) яңартып бетерүне;

2021 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкаруны;

проект документациясен төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт һәм ремонт объектларына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсенә һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына карап тикшерү өчен җибәрергә;

дәвам итәргә:

«2+1» принцибы буенча өч полосалы бер-бер артлы хәрәкәт итүне, шулай ук, юл өчен бүлеп бирелгән җитәрлек киңлектәге полосасы булган участокларда каршы килә торган транспорт агымнарын аерып, «2+2» принцибы буенча дүрт полосалы хәрәкәт итүне оештыру практикасын;

дүрт полосалы автомобиль юлларын хәрәкәтнең каршы юнәлешләрен бүлү системалары белән җиһазлау, шулай ук җәяүлеләрнең моның өчен каралмаган урыннарда машина йөрү өлешенә чыгуны чикләү өчен җәяүлеләр өчен киртәләр урнаштыру эшен;

автомобиль юлларын, беренче чиратта, мәгариф оешмалары, җәяүлеләр кичүе, автобус тукталышлары янындагы торак пунктларда, авария куркынычы булган автомобиль юлларының участокларында, халык күпләп җыела торган урыннарда ясалма яктырту линияләрен электр челтәрләренә үз вакытында тоташтыруны тәэмин итүне;

җәяүлеләр юл аша җир өстеннән чыгу урыннарына, юл чатларына килгән җирләрдә һәм автомобиль юлларының авария хәлендәге участокларында аркылы һәм буйлы тавыш полосаларын урнаштыруны;

автомобиль юллары участокларына реконструкция һәм ремонт ясала торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш полосаларын, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына караган Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең

патруль автомобильләре макетларын, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллануга юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашыруны;

ведомство карамагындагы автомобиль юллары участокларында, транспорт агымының туктаусыз хәрәкәтен, шул исәптән машина юлларыннан транспорт чараларына үтәргә комачаулый торган объектларны алуны тәэмин итеп, юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерү буенча чаралар күрүне;

берлектә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән (килешү буенча) юл хәрәкәтендә катнашучыларга Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны автомат рәвештә фотога һәм видеога төшерүнең автомат режимында эшли торган техник чаралары урнашкан урыннар һәм аларның географик координатлары күрсәтелгән геопозицияләре турында һәркем өчен файдалана алу мөмкинлеге булган мәгълүмат ресурслары ярдәмендә хәбәр итүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән (килешү буенча) һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары белән автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яисә ремонтлаганнан соң, аларны юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт стандартлары таләпләренә туры килү-килмәүгә тикшерү үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

«Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проектының «Юл челтәре» проектының төбәк өлеше булган юл эшчәнлеге программаларын формалаштырганда юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән инженерлык чараларын күздә тотарга;

балалар төркемнәрен оештырылган йөртү вакытында көн саен мәктәп автобусларын эксплуатацияләү мониторингын үткәрергә һәм кызыксынучы министрлыкларга һәм ведомстволарга алардан файдалана алу мөмкинлеге торышы, тизлек режимын саклавы турында мәгълүмат бирергә;

самокатлар һәм электр двигателе белән охшаш җайланмалардан файдаланучы затлар хәрәкәте тәртибен федераль дәрәҗәдә җайга салу турында тәкъдимнәр әзерләргә;

тизлекне мәҗбүри киметү чараларын урнаштыру буенча участокларны билгеләргә һәм 2021 елның 1 августына кадәр аларны урнаштыру планын (шул исәптән җәяүлеләр кичүе белән берләштерелгән ясалма тигезсезлекләрне) тормышка ашырырга);

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, 2021 елның 20 мартына кадәр муниципаль юл фондлары акчасының үзләштерелмичы калган өлешен 2021 елда юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча беренчел чираттагы чараларны башкаруга җибәрү турындагы тәкъдимнәрне, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юл күзәтчелеге идарәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) пассажирларны законсыз ташу фактларын булдырмау буенча уртак профилактик чаралар үткәрүне оештырырга;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.14 статьясын гамәлгә ашыру кысаларында кулга алынган транспорт чараларын саклау мәсьәләсен эшләп бетерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, 2021 елга юл эшләре программаларын башкару кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары үтә торган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының техник һәм эксплуатацияләү күрсәткечләрен арттыру чараларын тормышка ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

ата-аналарны балаларның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларын кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик рейдларга, олылар белән балаларны имин йөртү кагыйдәләре буенча аңлату эшләренә җәлеп итеп, ата-аналар патрульләре эшчәнлеген оештыруны тәкъдим итәргә;

белем бирү оешмалары эшчәнлегендә «www.sakla.ru» порталында урнаштырылган мәгълүмати материалларны куллануны оештырырга;

белем бирү оешмалары эшчәнлегендә «www.sakla.ru» порталында урнаштырылган мәгълүмати материалларны куллануны оештырырга;

соңгы дәресләрдә «куркынычсызлык минутлары»ын үткәрүне, шулай ук балаларга һәм ата-аналарга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту темасы буенча белем бирүгә, шул исәптән аларның киемендә яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм балаларны тотып тора торган җайланмаларны һәм куркынычсызлык каешларын файдалануга юнәлдерелгән чаралар (дәресләр, әңгәмәләр һәм инструктажлар) үткәрүне дәвам итәргә;

берлектә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар турында Татарстан Республикасы мәгълүматларының бердәм банкына кертелгән, шулай ук балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясендә исәптә торучы балигъ булмаганнарны хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чараларда һәм программаларда катнашуга җәлеп итүне оештырырга;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының яшь инспекторлары матбугат үзәкләренең журналист корпусына керә торган хәрәкәт яшь инспекторларына методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры белән (килешү буенча):

хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядларының республика форумын үткәрергә;

2020/2021 уку елы дәвамында мәгариф оешмаларында яшь инспекторлар эшчәнлеген оештыруны һәм балигъ булмаганнарны юлларда куркынычсыз тәртип кагыйдәләренә өйрәтүне тикшерергә;

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан 2021 ел дәвамында мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору" дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" ярдәмче программасы кысаларында алынган юл хәрәкәте иминлеге буенча җиһазларны максатчан куллануны тикшерергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары тарафыннан 2021 елның 1 июленә кадәр хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен эшләргә һәм расларга;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына:

хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары эшчәнлеген үстерү белән шөгыльләнүче педагогларны финанс белән тәэмин итү мәсьәләсен өйрәнергә;

Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында балалар лагерьларында хәрәкәтнең яшь инспекторларының профильле сменаларын оештырырга;

көндәлек контроль оештырырга:

балаларны мәктәп автобуслары белән оешкан рәвештә йөртү, шул исәптән тахограф һәм «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган борт навигация җайланмасы эшчәнлеге таләпләрен үтәргә;

балаларны Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә һәм балалар хәрәкәтенең имин маршруты схемалары нигезендә йөртергә;

укучыларга яктылыкны кире кайтара торган элементлар йөртергә һәм аларны куллану кирәклеге турында ата-аналар җыелышларында һәм сыйныф сәгатьләрендә искә төшерергә.

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына:

юл-транспорт травматизмын кисәтү эшчәнлегенә яшьләр оешмаларын һәм берләшмәләрен җәлеп итүне активлаштырырга, шул исәптән пропаганда чаралары, махсуслаштырылган акцияләр һәм семинарлар кысаларында;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча):

балалар һәм яшүсмерләр күпләп ял иткән вакытта, шул исәптән балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларында юл-транспорт җәрәхәтләнүләрен кисәтү буенча профилактик белем бирергә (юлларда куркынычсыз тәртип күнекмәләренә тематик кичәләр, уеннар, интерактив өйрәнүләр) үткәрергә;

җәйге каникуллар чорында «Дзержинец» балалар сәламәтләндерү лагере базасында хәрәкәтнең яшь инспекторлары конкурсының район этабы призерларының

профиль сменасын оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасының «Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары белән берлектә 2021 елның 1 апреленә кадәр түбәндәге мәсьәләләрне эшләргә:

тренерлар һәм җитәкчеләр өчен өстәмә ставкалар, шулай ук республикада картинг спортын үстерү өчен карта-клубларны матди-техник тәэмин итү;

хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары эшендә катнашучы балалар өчен картинг секцияләрендә бушлай дәресләр;

хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары эшендә катнашучы балалар өчен балалар автомобиль мәктәпләрендә укыту өчен ташламалы шартлар тудыру.

3. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән берлектә 2021 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша самокатоларны һәм электр двигателе белән охшаш җайланмаларны прокатка бирү мөмкинлеген гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

оператив җавап бирү һәм юл-транспорт һәлакәтләренең нәтиҗәләрен бетерүгә җәлеп ителә торган көчләрне һәм чараларны үз вакытында әзерлеккә китерү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның оператив фаразын көндәлек тапшыруны кызыксынган министрлыкларга һәм ведомстволарга тапшырырга;

берлектә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын җәлеп итеп, юл-транспорт һәлакәтләренә җавап бирү буенча елына кимендә дүрт тапкыр тактик-махсус өйрәнүләр уздырырга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белем бирү оешмаларын максималь колачлап, «Тормыш иминлеге өчен юлларда иминлек» темасына тормыш иминлеге нигезләре буенча дәрес уздырырга;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән һава шартларының начараюы һәм гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгуын СМС-хәбәр итү юлы белән оператив фаразлау турында халыкка мәгълүмат җиткерү буенча кәрәзле элемтә операторлары белән эшне дәвам итәргә.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләрне травмоүзәкләргә күчерү өчен санитария авиациясен нәтиҗәле һәм вакытында җәлеп итү алгоритмын эшләргә;

ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының эшчәнлеген туктатып тору һәм транспорт чаралары йөртүчеләрдә (транспорт чаралары йөртүчегә

кандидатларда) медицина ягыннан каршылыклар, медицина күрсәткечләре яисә транспорт чаралары белән идарә итүгә медицина чикләүләре булу (булмау) турында медицина бәяләмәсен гамәлдә булуын туктатып тору һәм гамәлдән чыгару буенча эшне оештырырга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсе белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чарасы белән идарә итүгә медицина каршылыклары, медицина күрсәткечләре һәм медицина чикләүләре исемлекләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1604 номерлы карарында күрсәтелгән транспорт чарасы белән идарә итүгә медицина каршылыклары, медицина күрсәткечләре һәм медицина чикләүләре булган транспорт чараларын йөртүчеләргә карата кирәкле мәгълүмат алмашуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча) 2021 елның 1 июненә кадәр «Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү» курсы буенча юл-патруль хезмәте хезмәткәрләрен укытырга.

6. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә юл сервисы объектларының санитар-экологик торышын, Татарстан Республикасында автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын тикшереп тору буенча экологик икеайлык чорларында эш оештырырга.

7. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы белән күздә тотылган җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү чараларын Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү буенча адреслы исемлегенә бары 2021 елда алар тарафыннан әлеге ярдәмче программаның шундый ук конкрет чараларын тигез финанслашу шарты белән генә кертергә;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә дәүләт хакимиятенең барлык башкарма органнарына «Транспорт системасы белән идарә итүнең бердәм платформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына масштабта керүне тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына Татарстан Республикасы территориясендә транспорт системасы белән идарә итүнең бердәм платформасын тиражлауны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча) Татарстан Республикасы «Тормыш эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет

учреждениесе түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының тәрбиячеләрен «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» программасы буенча белем алуын;

хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары җитәкчеләре өчен өйрәтү семинарлары үткәрүне.

9. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

яктылыкны кире кайтара торган элементларны тәүлекнең караңгы вакытында куллану кирәклеге турында материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга;

даими нигездә юл хәрәкәте иминлеге буенча социаль реклама урнаштырырга, ул җәяүлеләр катнашында балалар юл-транспорт травматизмын һәм юл-транспорт һәлакәтләрен киметүгә, мондый фактларны кулланганда транспорт чарасы белән идарә итү фактлары һәм фаҗигале нәтиҗәләр турында, муниципаль берәмлекләрдә исерек хәлдә транспорт чаралары белән идарә итү фактлары яки мондый хокуктан мәхрүм ителгән кешеләр тарафыннан транспорт чаралары белән идарә итү фактлары турында гражданнардан аноним мәгълүмат алу буенча телеграм-каналларны популярлаштыру хакында.

10. Тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы прокуратурасына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән берлектә (килешү буенча) транспорт чараларын йөртү стажы ике елдан да ким булган чыгарылыш сыйныф укучылары юл хәрәкәтендә катнашучыларның һәлак булуына яки яралануына китергән юл-транспорт һәлакәтләре кылган автомәктәпләрдә, шулай ук имтихан тапшыруның түбән күрсәткечләре булган Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсенең имтихан бүлекчәләрендә тикшерүләр үткәрергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына (килешү буенча):

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссияләре утырышларын әзерләүдә һәм уздыруда катнашуны дәвам итәргә;

муниципаль берәмлекләр тарафыннан каралган юл-транспорт һәлакәтләренең концентрациясе урыннарын, авария зоналарын, автомобиль юлларының потенциаль авария участокларын һәм аларда һәлак булучылар белән берничә юл-транспорт һәлакәтләре булган юл участокларын бетерү буенча чараларны, шулай ук муниципаль юл фондларының калдыклары хисабына үтәү планлаштырылган чараларны да килештерүдә һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тотуны тормышка ашыруда катнашырга;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау, шул исәптән балаларны куркынычсыз йөртүне тәэмин итү буенча ата-аналар белән перинаталь үзәкләрдә һәм бала тудыру йортларында тренинглар үткәрүне оештырырга;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары

федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә:

җир өсте җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләренә, юл чатларына һәм автомобиль юлларының авария участокларында һәм транспорт чараларының авышуларын булдырмау максатларында юлның бер өлеше кыры буйлап буй-буй шау-шу полосаларын урнаштыруны дәвам итәргә;

юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртүне күздә тоткан проект документациясен раслаганда тиешле проектларны һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә килештерү схемаларын тапшыруны тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертизаның төп бюросы» федераль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән организм функцияләренең билгеле бер категорияләре буенча инвалид дип танылган транспорт чаралары йөртүчеләренә карата кирәкле мәгълүмат алмашуны тәэмин итәргә;

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.8, 12.26 статьяларында, 20.25 статьясындагы 1 өлешендә каралган эшләрне карау нәтиҗәләре буенча суд органнары салган административ штрафларны түләтү һәм бурычлыларның транспорт чараларына арест салу эшчәнлеген активлаштырырга;

мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләү турында суд карарларының тиешле үтәлешен тикшереп торуны оештырырга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясындагы 4 өлеше нигезендә административ җәзаны үтәүдән читләшкән затларны административ җаваплылыкка тарту чараларын күрергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча) штрафлары 10 мең сумнан артып киткән бурычлыларга карата транспорт чаралары белән идарә итү хокукын чикләү буенча эшне активлаштырырга;

«Иннополис университеты» югары белем бирү автономияле коммерциягә карамаган югары белем бирү оешмасы Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча) 2021 елның 1 июленә кадәр юл хәрәкәте шартларында транспорт чаралары белән идарә итү хокукына имтиханны һәм теоретик имтиханны кабул итү өчен виртуаль чынбарлык комплексын сертификацияләү мәсьәләсен өйрәнергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына:

тәүлекнең караңгы вакытында яктылыкны кире кайтара торган элементлардан файдалану кирәклеге турында гражданнар җыеннарында аңлату эшләре үткәрергә;

2021 елның 1 июленә кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен) яңартып бетерергә;

2021 елның 1 августыннан 28 августына кадәр мәгариф оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкарырга;

2021 елның 10 декабренә кадәр 2022 елда муниципаль әһәмияттәге автомобиль

юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзергә;

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында һәлакәтләр булган очракта юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларына һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча башка чараларга чыгымнарны (ясалма тигезсезлекләрне, җәяүлеләр өчен чыгу юлларын һәм яктырту, коймалар урнаштыру, светофор җайга салуын оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау) җирле бюджет акчаларыннан карарга;

җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү эшләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт програм-масын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы акчасы исәбеннән финансланганда 2020 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программаларда җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү буенча шундый ук чыгымнарны җирле бюджет акчасы исәбеннән күздә тотарга;

җәяүлеләр өчен кичүләрнең мәгълүматлылыгын арттыру буенча эшне дәвам итәргә, шул исәптән яктылык диодлы яктырткыч белән юл билгеләре куюны, өстәмә яктырту куллануны күздә тотарга;

мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне 2021 елның 1 сентябренә кадәр гомуми белем бирү оешмаларында укырга әзерләү кысаларында беренче сыйныф укучыларын яктылык кайтару элементлары белән тәэмин итәргә һәм 2021 елның 1 гыйнварына кадәр аларны яңа ел бүләкләре комплектына кертергә;

автобуслар белән пассажирлар җибәрүне рөхсәт ителмәгән урыннарны бетерү буенча тулы чаралар күрергә;

ярты еллыкта юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышын, авыл җирлекләре башлыкларын һәм балалар белем бирү оешмалары (мәктәпләр һәм балалар бакчалары) директорларын, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмияттәге автомобиль юллары баланс тотучыларны чакырып, ярты елга бер мәртәбә үткәрергә;

муниципаль парковкаларны оештырганда аларны урнаштыру урыннарын һәм юл хәрәкәтен оештыру схемаларын Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән килештерергә;

автомобиль юллары участокларына реконструкция яки ремонт ясала торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш полосаларын, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу-ларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллануга юнәлде-релгән чаралар комплексын тормышка ашырырга;

каршы килә торган хәрәкәт полосасына чыгу аркасында барлыкка килә торган һәлак булучылары булган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү өчен, шулай ук җәяүлеләрнең юлны чыгу өчен каралмаган урыннарда машиналар йөри торган өлештән чыгуын чикләү өчен барьер тибындагы металл киртәләр, трослы һәм җәяү-леләр киртәләрен куюны дәвам итәргә;

автомобиль юллары участокларында, транспорт агымының туктаусыз хәрәкәтен, шул исәптән машина юлларыннан транспорт чараларына үтәргә комачаулый торган объектларны алуны тәэмин итеп, һәлак булучылары булган юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерү буенча чаралар күрергә;

юл сервисы объектларының юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килмәвен билгеләгәндә объектлар милекчеләренә җитешсезлекләрне бетерүне йөкләргә, таләп үтәлмәгәндә, мәгълүматны прокуратура органнарына җибәрергә;

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша (порталда хезмәт күрсәтелгәннән соң) самокатолар һәм электр двигателе белән охшаш җайланмалар прокаты буенча сервис оештырырга;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр эше кысаларында:

машина йөртүчеләрнең исерек хәлдә һәм идарә итү хокукы булмаган яки шундый хокуктан мәхрүм ителгән килеш транспорт чаралары белән идарә итү фактлары турында гражданнардан аноним мәгълүмат алу өчен телеграм-каналларны популярлаштырырга;

машина йөртүчеләрнең автотранспорт предприятиеләрендә транспорт чараларының техник торышын идарә итүгә һәм тикшереп торуны оештыру мәсьәләләрен карарга;

Казан шәһәре, Чаллы шәһәре һәм Түбән Кама районы башкарма комитетларына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча) трамвайларга техник тикшерү уздыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр җир өсте электр транспортының транспорт чараларын техник карауны уздыру турында» 2011 елның 30 декабрендәге 1240 номерлы карары белән билгеләнгән вакыт аралыгы белән тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры белән берлектә (килешү буенча):

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автобусларга техник күзәтү оештыру һәм үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 маендагы 741 номерлы карары белән билгеләнгән вакыт аралыгында автобусларга даими һәм вакытында техник тикшерү үтүне тәэмин итәргә;

2021 елның 1 февраленә кадәр автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларын, авария хәлендәге зоналарны, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм һәлак булучылар белән бердәнбер юл-транспорт һәлакәтләре булган юл участокларын туплауның потенциаль урыннарын бетерү чараларын эшләргә һәм 2021 елның 1 июленә кадәр аларны бетерү буенча планлаштырылган чараларны тәгәлләргә;

квартал саен хезмәт транспорт чараларының техник торышын, тиешле документлар һәм административ штрафлар булу-булмавын тикшерергә;

автомат режимда эшләүче Юл хәрәкәте кагыйдәләренең техник чараларын урнаштыру урыннары һәм аларның геопозицияләре, географик координатларын күрсәтеп, аларның геопозицияләре турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат ресурслары ярдәмендә хәбәр итүне тәэмин итәргә;

автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын төзегәннән,

реконструкцияләгәннән, капиталь ремонтлаганнан соң, аларны юл хәрәкәте иминлеге торышын бәяләү һәм эксплуатациягә кертү мөмкинлеге турында карар кабул итү өчен тикшерергә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм алардан килгән зыяннарны киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2019 ел, 18 декабрь, 1167 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

12. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин